**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт,Актаныш ав., 423740

Тел.(85552) 3-44-22,факс (85552) 3-44-14,E-mail:aktanysh@tatar.ru,www.aktanysh.tatarstan.ru

КАРАР

от 05.04.2022 № ПР-64

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

2022 елда Актаныш муниципаль районы территориясендә урнашкан гидротехник корылмаларны тикшерү комиссиясе турында

Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе, Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы, экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең Идел буе идарәсе 2022 елның 28 мартындагы 409 104 ПР-290-256-0 номерлы «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гидротехник корылмаларны тикшерүне оештыру турында»гы боерыгы, Актаныш муниципаль районы Уставы нигезендә, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Актаныш муниципаль районы территориясендә урнашкан гидротехник корылмаларны (алга таба - ГТС) тикшерү буенча комиссия төзергә.
2. Кушымта нигезендә Актаныш муниципаль районы территориясендә урнашкан гидротехник корылмалар тикшерүен үткәрү комиссиясе составын расларга.
3. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «2021 елда Актаныш муниципаль районы территориясендә урнашкан гидротехник корылмаларны тикшерү комиссиясе турында» 2021 елның 18 февралендәге ПР-28 номерлы карарын үз көчен югалткан дип санарга.
4. Районның рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Интернет мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында бастырып чыгарырга.
5. 4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Р.А.Ильясов

Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
_________ №___
кушымта

Актаныш муниципаль районы территориясендә урнашкан гидротехник корылмаларны тикшерү буенча комиссия

| | |
|---|---|
| Ильясов Рөстәм Алмаз улы | - Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе; |
| Сираева Лиана Рамил кызы | - Актаныш муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы вәкиле, Башкарма комитет җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары; |
| | Комиссия әгъзалары: |
| Шәрифҗанов Илназ Илдус улы | - Актаныш янгын сүндерү һәм коткару гарнизоны башлыгы (килешү буенча); |
| Гараев Данис Фәнис улы | - хезмәт күрсәтүче оешма җитәкчесе, «ПМК-6» ҖЧҖ директоры; |
| Хәмитов Рөстәм Рәшит улы | ТР Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының ГО өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру бүлегенең (Актаныш муниципаль районы буенча) әйдәп баручы консультанты; |

Кирәк булганда, комиссия утырышына Актаныш муниципаль районының авыл җирлекләре башлыклары чакырылырга мөмкин (килешү буенча).